# Мәктәп хәбәрчесе

**№1 (№4) январь 2019 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе гәзите*



**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**


***/Әниләргә киңәшләр /***

## *Баланың үсеш этаплары*

***(Яшь ярымга кадәрге чор)***

Дөньяга туганчы ук әни кеше баласын көтеп алуы һәм аңа карата җылы мөнәсәбәттә булуының әһәмияте турында сөйләшкән идек инде. Шулай ук әни балага кирәк булган иң мөһим икенче этап – ул баланың **тугач та яшь ярымга кадәр булган вакыты.** Шушы чорда зур дөньяга килгән сабый – ярдәмгә мохтаҗ иң зәгыйфь зат. Баланың беренче яшәү чоры **"Әни-Дөнья"** дип аталса, икенчесе **"Әни-зур дөньяда юл күрсәтүче"** дигән исем белән йөртелә. Чыннан да, әни аша бала дөнья белән таныша, тирә-юньне өйрәнә. Аның ачык йөзен, йомшак тавышын, сабырлыгын, тыныч һәм яратып караган күз карашын - һәммәсен дә бала тоя һәм сизеп тора.

Бала сәламәтлеге һәм үсеше өчен бу чорда иң мөһим өч шартның үтәлүе тиешле:

**1. Һәрвакыт әнисенең сабые янында булуы**: кечкенә баланы әнисеннән аеру һәр икесен дә зур стресс халәтенә китерә.

**2. Эмоциональ бәйләнеш**: янында күренеп йөрү генә җитми, ягымлы итеп каравы, йомшак матур тавыш белән эндәшүе, кулына алып иркәләве кирәк. Шулар аркылы бала күңел тынычлыгы ала.

**3. Хәленә керешү:** әни кеше баланың авазын ишетеп килә. Нинди теләк һәм хаҗәт белән чакыруын аңлый һәм ярдәм итә.

Әлеге таләпләр төгәл үтәлә икән, нәни бала күңелендә тынычлык урнаша. "Бу дөньяны өйрәнергә кирәк, монда куркыныч түгел икән, миңа зыян салмаячаклар"- дигән ышану барлыкка килә. Куркыну, борчылу, шикләнү булмаганда гына бала сәламәт үсеш алачак. Ләкин әни кеше сабырсызланып, бу шартларны үтәмичә калдырса, сабые тормышына гомер буе түләп бетерә алмаслык зур зыян салачак. Моны берничә мисалда карап үтәрбез.


**Бала янында әнисе урынына чит кешеләр булса.** Ул тынычсызлана, аңа рәхәт түгел, "минем ышанычлы юл күрсәтүчем юк, миңа бу дөньяда куркыныч һәм шомлы; тамагым тук, корыда, җылыда булсам да, җаным тынычсызлана; мине назлаган ягымлы караш юк, күңелемне юатучы йомшак тавыш юк, димәк, тирә-юньдә миңа золым янарга мөмкин".

**Бала янында ачулы, тынычсыз, арыган әни булса.** Бала әнисенең эчке кичерешләрен, ачулы тавышын, тынгысызлыгын, шомлы йөзен күреп үзе дә борчыла башлый. "Юл күрсәтүчем янымда, ләкин ул күңел тынычлыгы бирә алмый, миңа тирә-юньдәгеләр зыян салырга мөмкин, димәк, әнигә ышанып булмый". Әни кеше бу хәлдә калмасын өчен гаиләдә аның үзенә дә ышанычлы терәк кирәк. Әти кешенең ярдәме, гаиләсен аңлавы, яклавы, саклавы бик мөһим.

**Бала елаганда янына килмәү.** Нәни бала төрле авазлар салып яки елап үз янына чакырганда кайвакыт әниләр килмиләр: "Кычкырып арыгач туктар әле, эшләремне карарга кирәк" - диләр. Бу хәл көндәлек тормышка әйләнсә, бала күңелендә әнисенә ышаныч бетә, үзен ким итеп сизә. "Барыбер мине беркем дә ишетмәячәк, сорап торуның кирәге дә юк; нәрсәдер булдырырга маташу файдасыз; хыялланып та тормыйм, нәрсә булса шул булыр" – дип килешә бала. (Дәвамы икенче биттә)

***/ Укучылар иҗаты /***

## *Тылсымлы кич*



*Сара Насыйрова. VIII сыйныф*

## *Кышкы уйлар*

Ак юрганга төреп Җирне менә инде
Кыш килгәнен сизми калдым безнең якка.
Тын калганнар урман, кырлар һәм болыннар
Уйланам мин бүген менә шушы хакта.

Бар җир матур, кары ап-ак, һавасы саф
Салкын гына урнашкан шул хәзер тышта.
Шул суыкка түзәрләрме җәнлек-кошлар
Уйланам мин бүген менә шушы хакта.

Ничек табып, нәрсә ашап, кайда йоклап
Уздырырлар көн һәм төнне салкын чакта.
Бураннарны, җил – давылны җиңәрләрме
Уйланам мин бүген менә шушы хакта.

Табигатьтә юк диләр бит начар вакыт
Яз җиткәнче исән-имин булсын бар да.
Шатланырлар яз кояшын күреп алар,
Уйланам мин бүген менә шушы хакта.

***Әминә Туктамышева, VII сыйныф***

## Бердәнбер баянчыбыз

**/ Кызыклы әңгәмә /**



Безнең мәктәптән иң сәләтле укучыларыбыз Аксубайдагы Балалар һәм яшүсмерләрнең сәнгать мәктәбенә йөриләр. Бу уку йортына иң беренче юл салучы Гафиятуллин Самат Фәндәс улы булды. Шуның өчен без Саматтан мәктәптән тыш укуы турында сорашырга булдык.

**- Самат, син ничә яшьтән сәнгать белән шөгыльләнәсең?**

- Икенче сыйныфтан алып йөри башладым.

**- Бу мәктәптә ничә ел укырга кирәк?**

- Барлыгы җиде ел. Укырга зур теләк белән быел дүртенче ел йөрим. Документ алып чыгу өчен Аллаһ теләсә тагын өч ел укыйсы калды.

**- Баянда уйнарга өйрәнү – үз ихтыярың беләнме, әллә әти-әниең сайлавымы?**

- Үземә бик ошый баянда уйнау. Һәр бәйрәмдә : "Самат, әйдә, уйнап бәйрәмебезне матурла инде!" дип, күңелемне күтәрәләр. Әле бит "Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз" мәкален дә онытырга ярамый.

**- Бу түгәрәктә сиңа аеруча нәрсә ошый?**

- Күп дуслар таптым, һәрберсе белән түгәрәктән тыш аралашып торабыз.

**- Баяннан тыш башка уен коралларында уйнарга өйрәнәсезме?**

- Узган елдан бирле балалайкада да уйный башладым.

**- Аксубай бездән шактый ерак бит. Юлда йөрү авырлык тудырмыймы?**

- Юк, кешеләр кирәк-ярак алыр өчен дә юлга чыгып китәләр. Ә мин һөнәр алыр өчен йөрим. Һөнәр, минемчә, товардан кадерлерәк.

**- Киләчәктә бу һөнәрне кулланырга уйлыйсыңмы?**

- Хәзерге көндә бәйрәмнәрдә, төрле конкурсларда оркестр белән йөрибез. Әлбәттә, киләчәктә концертларда катнашырмын дип өметләнәм.

***Әңгәмәне Зөлфирә Сафиуллина һәм Виктория Нукина алып барды***

**/ Безнең уңышлар /**




## Спорт ярышлары

Яңа елның беренче ае безнең мәктәп өчен традицон спорт төрләрендәге җиңүләр белән башланып китте. 18 гыйнварда "Кызыл Шәрык" ААҖ призына Әлки районы үзәге Базарлы Матакта уздырылган **билбау көрәше** буенча **Республика** беренчелегендә үз авырлыкларында **Хәбибрахманов Ильяс** – 1, **Камалов Илдус** – 3 урыннарны яуладылар. (Остазлары – **Илһам Камалов**)

Гыйнвар аенда Савгач урта мәктәбе базасында социалистик хезмәт герое М.А.Михеев истәлегенә шашка һәм шахмат буенча район турниры уздырылды. Ярыш нәтиҗәләре буенча безнең мәктәп командасы 3нче урынга ия булды. Шәхси беренчелектә **Нурматов Муса** (V сыйныф) шулай ук 3нче урынны алды.

## Дәрестән тыш эшчәнлек

Гыйнвар аенда Район мәктәптән тыш эшчәнлек үзәге тарафыннан "Синең җирдәге эзең" иҗади эшләр конкурсы уздырылды. Бу бәйгедә безнең мәктәптән "Рәсем" номинациясендә **Насыйрова Сарага** – I, **Әхмәтҗанова Лилиягә** – II урыннар бирелде. (Остазлары – **Зөлфия Зарипова**). "Гадәти булмаган эшләнмә" номинациясендә Сафиуллина Зөлфирә – I, Туктамышева Әминә – 2 урыннарга ирештеләр. (Остазлары –**Хәйруллина Рузилә Әдһәм кызы**)

Андый кешеләрдә үскәч дөрес юл белән мал табу, яки үз алдына зур максатлар кую теләге булмаячак. Нәрсәнедер теләү начарлык яисә буш хыял буларак кабул ителәчәк.

**Бала озак вакыт елап торгач кына аның янына килү.** Һәрнәрсәне елап һәм даулап кына алырга күнеккән бала күңелендә: "Үзеңнең хаҗәтеңне тормышка ашыру өчен һәрнәрсәне көрәшеп алырга кирәк"- дигән уй яши башлый. Алар арасыннан яхшы эшкуарлар чыгарга мөмкин, чөнки алар нинди юл белән булса да үз максатларына ирешергә, һәрвакыт җиңәргә тырышалар. Шулай да бу бик уңай һәм сәламәт яшәү рәвеше дип әйтеп булмый. Мондый кешеләр үзләренең якыннарыннан да, тирә-юньдәгеләрдән дә матур гына сорый белмиләр. Алар һәрвакыт бәхәсләшәләр, әрләшәләр, яныйлар, куркыталар һ.б. Күпвакыт мондый күренеш якыннарының читләшүенә китерә.

(Дәвамы алдагы саннарда)

***Бакча төркеме тәрбиячесе Гөлүсә Насыйрова***

/ Чал тарихта эзле без /

## Түбән Майнада беренче баскычлы совет мәктәбе оешу

1917 елгы октябрь инкыйлабы гасырлар дәвамында яшәп килгән мәгариф системасына тамырдан үзгәрешләр кертә. Авыллардагы элеккеге мәктәп-мәдрәсәләр урынына тулысынча дәүләт карамагында торган беренче һәм икенче баскычлы совет мәктәпләре оештырыла. Түбән Майна авылында беренче баскычлы совет мәктәбе (4 сыйныфлы башлангыч мәктәп) 1918 елда эшли башлый. Мәктәп өчен элеккеге мәдрәсә бинасы файдаланыла. 1920 еллар ахырына бу бина нык тузганлыктан сүтеп ягыла. Шуннан соң укыту, утынын ягу хисабына, мәктәпне үз йортларына керткән кешеләрнең өйләрендә алып барыла. 1930 елдан алып мәктәп кулак буларак сөрелгән Сөнгатуллин Ибраһим, Әхмәров Гыйләҗ, Сәгъдиев Фәсхетдин, Латыйпов Хәсәнша һәм аның хатыны Нурияләрнең өйләре буйлап күчеп йөри. Мәчет бинасын да күпмедер вакыт мәктәп өчен файдаланулары турында хәбәрләр калган, ләкин кайсы елны икәнлеге төгәл билгеле түгел. 1937 нче елда лагерьларга озатылган Нәҗметдинов Фәсах, Әхмәров Сираҗ һәм тагын 1-2 кешенең өйләрен күчереп һәм бер-берсенә ялгап күтәреп, “яңа” мәктәп бинасы корыла. Бу бина хәзерге мәктәп йортының Нәҗметдинов Фәрхәтләргә каршы турысында урнашкан булган һәм 1960 еллар уртасына чаклы файдаланылган.

1920 еллар дәвамында һәм 1930 еллар башында безнең тирәдәге авылларның барчасында да башлангыч мәктәпләр генә булган. 1932 елда Такталы авылында тирә-якта бердәнбер булган җидееллык мәктәп ачыла. Шул ук елларда Кызыл Баран авылы янындагы элеккеге алпавыт утарында “Новый мир” дигән интернат-мәктәп эшли башлый. Безнең авылның башлангычтан соң белемнәрен дәвам итәргә теләгән укучылары шул мәктәпләргә йөреп укыганнар. Ләкин ул елларда тормыш шартлары бик авыр булганлыктан, күпчелек балалар башлангыч мәктәп белеме белән канәгатьләнгәннәр. 1939 елда Югары Майна авылында җидееллык мәктәп ачылгач, безнең авыллар укырга шунда йөри башлыйлар.

1920-30 елларда авыл мәктәбенең эшчәнлеген тотрыклы дип бәяләп булмый. Мәктәпнең ныклап аякка басып китә алмавына халыкның ярлылыгы һәм матди базаның җитешсезлегеннән бигрәк, укытучы кадрлар составының тотрыксызлыгы сәбәп булып тора. 1918-1946 еллар арасында Түбән Майна мәктәбендә эшләгән укытучыларның барысы да читтән китерелгән кешеләр була. Аларның иң озак эшләгәннәре дә безнең мәктәптә 2-3 елдан артык тоткарланмаган. Кадрларның еш алмашынуы укытуда эзлеклелекнең сакланмавына, эшнең соңгы нәтиҗәсе белән кызыксынмауга һәм ахыр чиктә шул мәктәптә укыган балаларның белем сыйфатының түбән булуына китерә.

Укытучыларның читтән китерелүе авылның үзендәге зыялыларның яңа тәртипләрне кабул итә алмаганын һәм хакимият каршында ышанычсыз саналуларын күрсәтә. Үзебезнең авылда укытучы эшен алып барырлык кешеләр, әлбәттә, булган. Ләкин алар мулла яки кулак гаиләсеннән чыгу сәбәпле, туган җирләрендә яши һәм эшли алмаганнар. Мисал өчен, 1919-1920 елларда мөгаллимлек иткән Тәрҗеманов Гаяз (Бәдретдин мулланың улы) “сәнәкчеләр сугышы” вакытында баш күтәргән халык белән китеп юкка чыга. Шулай ук, үзебезнең авылдан чыгышлы укытучылар Нигъмәтуллин Вәлиәхмәт һәм Хәйретдинов Хәлим чит авылларда эшләргә һәм яшәргә мәҗбүр булганнар.

/ Күренекле шәхесләр /

## Яңа дәвернең беренче мөгаллиме



1918 елның гыйнварында чыккан мәктәпне чиркәүдән аеру турындагы декрет буенча уку йортларында дини белем бирү тыела. Дини-милли тәрбия урынына коммунистик тәрбия бирү максат итеп куела.Элеккеге мулла -мөгаллимнәр укыту эшеннән читләштереләә. Аларга алмашка дәүләттән хезмәт хакы алып эшләүче укытучылар куела. Шуңа да карамастан, татар мәктәпләрендә һәм мәчетләрдә дин сабагын өйрәтү 1929 елга кадәр дәвам итә. Гражданнар сугышы барган шартларда большевиклар дингә бәйләнергә батырчылык итмиләр һәм мәктәпләрдә дин укытуга күз йомып киләләр. Шуның өстенә, мәктәп укытучыларының барысы да диярлек элеккеге мәдрәсә шәкертләре булганлыктан, халык теләге һәм үзләренең гадәтләре буенча балаларга дини белемнәрне дә бирергә тырышканнар.

Түбән Майнаның беренче совет укытучысы Баганалы авылыннан килгән Хәбибуллин Хәлил исемле кеше була. Халык хәтерендә аның исеме авылда 1918 елның февралендә булып узган чуалышларга бәйле рәвештә искә алына. Авылдагы күтәрелешне бастырырга килгән кызыллар отряды мәчет янында җыелган халыкны туздырыр өчен пулеметтан ут ача. Шунда бер пуля, мәдрәсә тәрәзәсеннән кереп, Хәйруллин Әһлиулла дигән малайны яралый. Бу хәлдән соң Хәлил мөгаллимнең урамга чыгып “балаларны атасыз бит, туктагыз!” – дип кычкырганлыгын сөйлиләр. Исеме халык хәтерендә сакланганлыктан, Хәбибуллин Хәлил авылда 1-2 ел дәвамында эшләгәндер диергә нигез бар. Ул укытучы булып торган дәвердә дини белемнәр укытылуы турында да хәбәрләр калган.

Түбән Майнадан киткәннән соң, Хәбибуллин Хәлил үзенең туган авылы Баганалы мәктәбендә эшли. 1925 елда аның җитәкчелегендә Баганалыда яңа зур мәктәп бинасы төзелә. Хәлил мөгаллим озак еллар мәктәп директоры булып эшли. Аның тырышлыгы белән 1936 елда башлангыч мәктәп җидееллык итеп үзгәртелә. Халык мәгарифе өлкәсендәге фидакарь хезмәтләре өчен Хәбибуллин Хәлилгә Татарстан АССРның һәм РСФСРның атказанган укытучысы исемнәре бирелә, һәм Ленин ордены белән бүләкләнә.

**/ Кызыклы әңгәмә /**

## *Көрәш түгәрәге батырлар әзерли*

Менә икенче ел инде мәктәбебездә милли көрәш түгәрәге уңышлы эшләп килә. Аның җитәкчесе җитәкчесе Илһам абый Камалов үз вазифасын бик яратып һәм җиренә җиткереп башкара. Газета укучыларыбызны түгәрәк эшчәнлеге белән таныштыру максатыннан Илһам абый белән әңгәмә уздырырга булдык.

**- Илһам абый, без сезне беренче чиратта авылыбызның хуҗалык җитәкчесе буларак беләбез. Шундый җаваплы урында эшләп тә, түгәрәкне алып барырга кайдан вакыт табасыз?**

- Берничә эшне бергә алып бару, әлбәттә, җиңел түгел. Ләкин теләк булса, барысына да вакыт табып була.

**- Үзегез көрәшкә ничек өйрәндегез? Үзлектәнме?**

- Мин кечкенәдән көрәшкә өйрәнеп үстем, бу һөнәрне олылардан үзләштердем.

**- Шәкертләрегез белән ярыш, конкурсларда катнашасызмы?**

- Әйе, төрле ярышларда еш катнашабыз. Иң беренче җиңүебез 2016 елның көзендә булды. Болгарда узган дзюдо буенча ярышта үзебезнең Илнар 3нче урынны алып кайтты. Шуннан бирле бик күп ярышлырда катнашып, алдынгы урыннарны яулап киләбез.

**- Сез эш нәтиҗәләрегездән канәгатьме?**

- Бик канәгать, чөнки без әле күптән түгел генә эшли башладык.

**- Алдагы елларда да түгәрәкне алып барырга ниятлисезме?**

- Әйе, егетләрнең үзләрендә теләкләре булса, исәнлек булса, шөгыльләнергә шат булам. Узган елдан алып көрәшкә башлангыч сыйныф укучылары да йөри башлады. Димәк, киләчәгебез бар.

**- Сез кайсы шәкертегезне аеруча сәләтле дип саныйсыз?**

- Барысы белән дә горурланам, берсен дә аермыйм. Ләкин Аксубай спорт мәктәбенә йөреп тәҗрибә туплаган егетләр алдынгылыкта бара. Болар безнең Илдус, Ильяс, Әхмәт, Халидлар. Данил ярышларда катнашмаса да, бик яхшы көрәшә.

**- Түгәрәк эшчәнлеген тагын да уңышлы иту өчен нинди чаралар күрергә кирәк?**

- Спортзалда көрәш өчен махсус келәм кайтарылса, бик яхшы булыр иде.

**- Илһам абый. Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт. Киләчәктә үзегезгә һәм шәкертләрегезгә исәнлек-саулык һәм зур уңышлар теләп калабыз**




Илһам Камалов мәктәп Сабан туенда көрәшне оештыра. 2018 ел.

***Әңгәмәне Нәзирә Әхмәтова һәм Сара Насыйрова алып барды***

**/ Котлыйбыз! /**

Гыйнвар аенда туучыларны туган көннәре белән котлыйбыз!

20нче гыйнварда балалар бакчасына йөрүче Мансурга 3 яшь тулды! Яңа елның беренче көнендә Замалетдинова Инзиләгә 12 яшь, Камалов Илдуска 13 яшь, 7нче гыйнварда Хәбибрахманова Мәрьямгә 11 яшь, 18нче гыйнварда Закирова Ләйсәнгә 7 яшь тулды!





Хәснуллин Фәнис абыйның да гомер бәйрәме 1нче гыйварда булып узды!

Бу көн шулай күңелледер
Сез туганга,
Дөнья шулай кояшлыдыр
Сез булганга.

**/ Күңелле тәнәфес /**

***КӘРӘЗЛЕ КРОССВОРД***




Бу кроссворд “Татарча башваткычлар” электрон гәзитеннән алынды

***Мәктәп мәзәкләре***

Татар теле дәресе. Укытучы:
- Мин йөткерәм, ул йөткерә, син йөткерәсең. Бу нинди заман?
- Кышкы заман!

Туп директор кабинеты тәрәзәсенә очып барып җиткәнче үк, укучылар футбол уйнаудан качыш уйнауга күчтеләр.

Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Гөлчәчәк Шәмәрданова
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева, Алия Гыйззәтуллина
Виктория Нукина, Нәзирә Әхмәтова
Зөлфирә Сафиуллина, Рузилә Мөхәммәтова
Сара Насыйрова